РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 27 нче ноябре** **Чистай шәһәре** **№41/4**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны тыңлап, фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча 2019 елның 2 октябрендә үткәрелгән ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы комиссия бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге Җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең Чистай муниципаль районы территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә, алар Чистай шәһәр Советының 19.12.2012 ел, №18/7 карары белән расланган( Чистай шәһәр Советының 2016 елның 30 июнендәге №7/1, 25.08.2016 ел №8/4, 27.04.2017 ел №14/5, 28.09.2017 ел №18/4, 02.11.2017 ел №19/2, 14.12.2017ел №20/13, 21.03.2018ел №23/5, 29.08.2018ел №27/1, 24.10.2018ел №28/5, 25.12.2018ел №30/12, 28.02.2019 ел №32/1, 30.04.2019 ел № 34/6, 11.06.2019ел №35/4, 04.09.2019 ел, №37/3 карарлары редакциясендә):

- Ж-1 “Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы” торак төзелеше территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Жуковский ур., 17В, шул исәптән кадастр номеры 16:54:160310:65, мәйданы 804,0 кв. м. булган җир кишәрлеген Д-3 “Мәгариф объектларын һәм фәнни комплексларны урнаштыру зонасы” төзелеш корылмалары зонасына кертергә” (1 нче кушымта);
- Р-1 “Рекреацион-ландшафт территорияләре зонасы” территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре, К.Маркс ур., 92-ц, шул исәптән кадастр номеры 16:54:150102:57, мәйданы 1719,0 кв. м. булган җир кишәрлеген Д-1 “Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона” төзелеш корылмалары зонасына кертергә” (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары М. И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов

Чистай шәһәр Советының
2019 елның 27 нче ноябрендәге
41/4 нче номерлы карарына
1 нче кушымта

Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең территорияне шәһәр төзелеше зоналарына бүлү картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:



Чистай шәһәр Советының
2019 елның 27 нче ноябрендәге
41/4 нче номерлы карарына
2 нче кушымта

Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең территорияне шәһәр төзелеше зоналарына бүлү картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:

